ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.09.2016 Казан ш. № 87

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау хакында

2004 елның 27 июлендәге "Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында" № 79-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге "Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә карата конкурс турында" № 112 указы, 2003 елның 16 гыйнварындагы "Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте турында" № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифаларын биләү буенча кандидатларны сыйфатлы сайлау һәм Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында кадрлар резервын нәтиҗәле формалаштыру максатларында боерык бирәм:

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс үткәрү турында нигезләмәне расларга.
2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис С.Е. Иванов.

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 15.09.2016
№ 87 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында
Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын
биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс үткәрү турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс (алга таба – Конкурс) үткәрүнең тәртибен, шартларын һәм методикасын билгели.

Конкурс Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә (алга таба – гражданлык хезмәте) карата тигез мөмкинлеккә ия булуының конституциячел хокукын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазифада үсү хокукын тәэмин итә.

1.2. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында (алга таба – Дәүләт комитеты) конкурс 2004 елның 27 июлендәге "Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында" № 79-ФЗ Федераль законның 22 статьясы, Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге "Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә карата конкурс турында" № 112 указы, 2003 елның 16 гыйнварындагы "Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте турында" № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 14 мартындагы "Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында" № ПУ-127 указы нигезендә үткәрелә.

Конкурс Дәүләт комитетында гражданлык хезмәтенең вакант вазифаларын (кадрлар резервындагы гражданлык хезмәте вазифаларын) биләүгә дәгъва кылучыларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның әлеге вазифага карата билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Дәүләт комитетында гражданлык хезмәтенең вакант вазифаларын биләүгә карата конкурс Дәүләт комитетындагы гражданлык хезмәтенең вакант вазифасы булган структур бүлекчә җитәкчесенең Дәүләт комитетындагы кадрлар һәм юридик эш секторы белән килештерелгән дәлилле язмача мөрәҗәгате (шушы Кушымтага карата 1 кушымта) нигезендә Дәүләт комитеты рәисе карары белән игълан ителә.

Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертелүгә карата конкурс Дәүләт комитетындагы кадрлар һәм юридик эш секторы тарафыннан, Дәүләт комитетында

дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифаларын биләү буенча белгечләрдә мөмкин булган ихтыяҗны һәм Дәүләт комитетында булган кадрлар резервын ел саен бәяләү нәтиҗәләре буенча оештырыла.

Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертелүгә карата конкурс Дәүләт комитетының конкурс комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә үткәрелә.

1.4. Дәүләт комитетында гражданлык хезмәтенең вакант вазифаларын биләүгә карата конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

"җитәкчеләр" һәм "ярдәмчеләр (киңәшчеләр)" категориясендәге гражданлык хезмәте вазифасы вәкаләтләрен билгеләнгән бер чорда биләүгә билгеләнгәндә;

аларга билгеләү һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган, "җитәкчеләр" категориясендәге гражданлык хезмәте вазифаларына билгеләнгәндә;

вакытлы хезмәт контрактын төзегәндә;

2004 елның 27 июлендәге "Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында" № 79-ФЗ Федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә каралган очракларда, – гражданлык хезмәткәрен гражданлык хезмәтенең башка вазифасына билгеләгәндә;

гражданлык хезмәтендәге кадрлар резервына кертелгән гражданлык хезмәткәрен (гражданны) гражданлык хезмәте вазифасына билгеләгәндә.

1.5. Дәүләт комитетында гражданлык хезмәтенең вакант вазифаларын биләүгә карата конкурс түбәндәге очракларда үткәрелмәскә мөмкин:

алар буенча вазифаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрне файдалануга бәйле булган, Дәүләт комитеты боерыгы белән раслана торган вазифалар исемлеге буенча аерым гражданлык хезмәте вазифаларына билгеләгәндә;

Дәүләт комитеты рәисенең карары буенча, гражданлык хезмәтенең кече вазифалары төркеменә карый торган гражданлык хезмәте вазифаларына билгеләгәндә.

1.6. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

сәләтләре һәм һөнәри әзерлеге нигезендә Россия Федерациясе гражданнарының гражданлык хезмәтенә тигез үтеп керүдәге конституциячел хокукларын, шулай ук гражданлык хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазифада үсү хокукларын тәэмин итү;

гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә аеруча туры килә торган кандидатларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатлар саны арасыннан сайлап алу;

гражданлык хезмәте вазифаларын биләү өчен Дәүләт комитетының кадрлар резервын формалаштыру.

1.7. Конкурсларны үткәргәндә хәл ителә торган мәсьәләләр:

барлык кандидатлар өчен дә алар тарафыннан конкурс биремнәре һәм процедуралары үтәлгәндә тигез шартларны тәэмин итү;

гражданлык хезмәте мәдәниятенә, һөнәри вәкаләтчелегенә һәм шәхси-эшлекле сыйфатларына туры килү критерияләре нигезендә кандидатларны бәяләү;

конкурста катнашучылар арасыннан Дәүләт комитетында гражданлык хезмәтенең вакант вазифасы (кадрлар резервындагы гражданлык хезмәте вазифасы) таләпләренә туры килә торган затларны алар тарафыннан конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләрен чагыштыру юлы белән ачыклау.

## 2. Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм аның эшләү тәртибе

2.1. Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге "Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә карата конкурс турында" № 112 указы нигезендә Дәүләт комитетында даими гамәлдә булган конкурс комиссиясе төзелә, аның составы Дәүләт комитеты боерыгы белән раслана. Комиссия составына кертелгән вазифаи затларның шәхси составы үзгәргәндә, Дәүләт комитеты боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

2.2. Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итү конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан гамәлгә ашырыла. Конкурс комиссиясе булмый торган чорда аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясенең сәркатибе конкурс комиссиясенең эшен тәэмин итә (гаризаларны терки, кабул итә, эшләрне формалаштыра, конкурста катнашучыларны исәпкә алу журналын алып бара, конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерә һ.б.).

2.4. Дәүләт комитетының конкурс комиссиясе составына Дәүләт комитеты рәисе, Дәүләт комитеты рәисенең урынбасарлары, Дәүләт комитетындагы кадрлар һәм юридик эш секторы вәкилләре, Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Дәүләт комитетының гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс үткәрелә торган структур бүлекчәсе җитәкчесе, Дәүләт комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук Дәүләт комитеты гаризасы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан бәйсез экспертлар сыйфатында чакыртыла торган фәнни, мәгариф һәм бүтән оешмаларның вәкилләре – гражданлык хезмәте белән бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр, экспертларның шәхси мәгълүматларын күрсәтмичә.

Конкурс комиссиясе составына кертү өчен Дәүләт комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет вәкилләре кандидатуралары әлеге совет тарафыннан Дәүләт комитеты рәисенең гаризасы буенча тәкъдим ителә.

Дәүләт комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет әгъзаларының һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясендәге барлык әгъзалар санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.5. Алар буенча вазифаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган гражданлык хезмәте вакант вазифасын

биләүгә карата конкурс үткәрелгәндә конкурс комиссиясенең составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы законнары нигезләмәләрен исәпкә алып формалаштырыла.

2.6. Конкурс комиссиясенең составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырдай мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге калмаслык итеп төзелә.

2.7. Конкурс комиссиясенең утырышы гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын (кадрлар резервындагы гражданлык хезмәте вазифаларын) биләүгә карата кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгәр дә анда аның әгъзалары саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашкан очракта, тулы хокуклы булып санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик комиссиянең гражданлык вазифаларын биләүче әгъзалары составында гына үткәрү рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе:

конкурсны үткәрү шартларын регламентлый торган документларны, аны үткәрү өчен кирәкле булган методик һәм бүтән материалларны раслый;

гражданлык хезмәте вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъвалык итүче гражданнарга конкурсны үткәрү шартлары турында мәгълүмат җиткерә һәм консультацияли;

кандидатлардан алынган гарызнамәләр буенча конкурс документларын бирә;

кандидатлар тарафыннан гражданлык хезмәте вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата тапшырылган документларны тикшергәннән соң, конкурс комиссиясе конкурсның икенче этабына кертелгән кандидатларның исемлеген раслый;

кандидатларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяли;

конкурска йомгак ясау, кандидатны конкурста җиңүче итеп тану турында карар кабул итә, аны Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертү өчен тәкъдим итә.

2.9. Конкурс комиссиясенең конкурсны үткәрү нәтиҗәләре буенча карары ачык тавыш бирү нигезендә аның утырышта катнашкан әгъзалары тавышларының гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавыш биргәндә конкурс комиссиясе әгъзаларының фикере "риза" яки "каршы" сүзләре белән белдерелә. Тавышлар тигез булган очракта конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәл иткеч була. Конкурс комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасы, кабул ителгән карар белән риза булмаган очракта, махсус фикерен белдерергә мөмкин, ул конкурс комиссиясе утырышының беркетмәсендә теркәлә һәм конкурс комиссиясендәге әлеге әгъзаның имзасы белән беркетелә.

2.10. Конкурс комиссиясенең карары кандидат юклыгында кабул ителә һәм аны гражданлык хезмәте вазифасына билгеләү (аның ризалыгы белән кадрлар резервына кертү), яисә моннан баш тарту өчен нигез булып тора.

2.11. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре конкурс комиссиясе утырышының беркетмәсенә кертелә, ул конкурс комиссиясенең рәисе, рәисе урынбасары, сәркатибе һәм утырышта катнашкан әгъзалары тарафыннан имзалана. Шул ук вакытта конкурс комиссиясе тарафыннан гражданлык хезмәтенә беренче мәртәбә билгеләнгәндә граждан өчен яки гражданлык хезмәткәрен Дәүләт

комитетының башка төркемдәге яки категориядәге гражданлык хезмәтенә күчерелгәндә сынау чорының озынлыгы буенча киңәш бирелергә мөмкин.

2.12. Конкурс үткәрүне, конкурс комиссиясе эшен турыдан-туры оештыру һәм тәэмин итү Дәүләт комитетындагы кадрлар һәм юридик эш секторы тарафыннан башкарыла.

## 3. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста катнашу өчен Дәүләт комитетында гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча кандидатларга карата таләпләргә җавап җирә торган һәм шушы Нигезләмәнең 3.8 пунктында каралган чорда шушы Нигезләмәнең 3.4 пунктында аталган документларны тапшырган гражданнар кертелә.

3.2. Граждан (граждан хезмәткәре), гражданлык хезмәтенең вакант вазифасына (кадрлар резервындагы гражданлык хезмәте вазифасына) карата квалификация таләпләренә җавап бирмәвенә бәйле рәвештә, шулай ук Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турындагы законнарында гражданлык хезмәтенә керү һәм аны үтү буенча билгеләнгән чикләмәләр аркасында конкурста катнашуга кертелми.

3.3. Дәүләт комитетында гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча кандидатларга карата таләпләр (шушы Нигезләмәгә карата 3 кушымта) Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турындагы законнары нигезендә билгеләнгән.

3.4. Россия Федерациясенең конкурста катнашырга теләк белдергән гражданы Дәүләт комитетына түбәндәгеләрне тапшыра:

а) шәхси гариза (шушы Нигезләмәгә карата 2 кушымта);

б) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы № 667-р карары белән расланган рәвештә, үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, фотосын (4х6 см, чатсыз) теркәп;

в) паспорт яки аны алмаштыра торган документ (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә) күчермәсе;

г) кирәкле һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслый торган документлар:

хезмәт кенәгәсенең (хезмәт итүгә (эшкә) бәйле эшчәнлек беренче мәртәбә гамәлгә ашырыла торган очраклардан кала) нотариаль яктан яки хезмәт итү (эш) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе яки гражданның эшкә бәйле (хезмәт итү) эшчәнлеген раслый торган бүтән документлар;

белем алу турында һәм квалификация турындагы документларның күчермәләре, шулай ук, ихтыяры буенча, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яки бирелүне раслый торган документларның, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирелү турындагы документларның нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәләре;

д) гражданда гражданлык хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачаулый торган чирләрнең булмавы турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау

министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге № 984н боерыгы белән расланган 001-ГС/у исәп рәвеше);

е) 2004 елның 27 июлендәге "Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында" № 79-ФЗ Федераль законда, бүтән федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган бүтән документлар.

3.5. Дәүләт комитетының конкурста катнашу теләген белдергән гражданлык хезмәткәре гаризаны Дәүләт комитеты рәисе исеменә тапшыра.

3.6. Бүтән дәүләт органында вазифа биләгән, конкурста катнашу теләген белдергән гражданлык хезмәткәре Дәүләт комитетына Дәүләт комитеты рәисе исеменә шәхси гариза һәм үз куллары белән тутырылган, имзаланган һәм гражданлык хезмәткәре гражданлык хезмәте вазифасын үтә торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы № 667-р карары белән расланган рәвештә анкета тапшыра, фотосын (4х6 см, чатсыз) теркәп.

3.7. Гражданның (граждан хезмәткәренең) ризалыгы белән, аңа дәүләт серен яки закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт бирү процедурасы рәсмиләштерелә, әгәр дә граждан (гражданлык хезмәткәре) дәгъва кыла торган гражданлык хезмәте вазифасы буенча вазифаи бурычларны башкару мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булса.

Граждан тарафыннан Дәүләт комитеты рәисе исеменә тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге тикшерелергә тиешле.

Гражданлык хезмәткәре тапшырган белешмәләрнең дөреслеген тикшерү бары тик ул Дәүләт комитетында гражданлык хезмәтенең иң югары вазифалар төркеменә карый торган гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә карата конкурста катнашкан очракта гына гамәлгә ашырыла.

3.8. Конкурста катнашу буенча документлар кандидатлар тарафыннан Дәүләт комитетының кадрлар һәм юридик эш секторына конкурс үткәрелү турындагы мәгълүмат хаты Дәүләт комитетының Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталындагы рәсми сайтында һәм "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәренең дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылганнан соң 21 көнлек чорда тапшырыла.

3.9. Хөрмәткә лаек сәбәпсез документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданнан аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Хөрмәткә лаек сәбәп буенча документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда Дәүләт комитеты рәисе аларны карап тикшерүнең вакытын күчерергә хокуклы.

## 4. Конкурсны үткәрү методикасы

4.1. Конкурсны үткәргәндә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларына таянган, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы

законнарына каршы килми торган конкурс биремнәре һәм процедуралары кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерияләре Дәүләт комитетында гражданлык хезмәте вазифаларына белдерелә торган квалификация таләпләре нигезендә эшләнгән.

Конкурс үткәрелә торган вазифаларның төркеменә һәм категориясенә карап, конкурста катнашучыларны бәяләү критерияләре һәм сайланган бәяләү методлары үзгәртелергә мөмкин.

Конкурста катнашучыларны бәяләү критерияләренең якынча исемлеге һәм кыскача эчтәлеге шушы Нигезләмәгә карата 4 кушымтада китерелде.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу алар тарафыннан конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.4. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.4.1. Беренче этапта Дәүләт комитетының кадрлар һәм юридик эш секторы түбәндәгеләрне оештыра:

конкурс үткәрелү турындагы мәгълүматны әзерли һәм Дәүләт комитетының рәсми сайтында һәм "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәренең дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыра, әлеге мәгълүмат түбәндәгеләрне үз эченә ала: гражданлык хезмәтенең вакант вазифасының (кадрлар резервындагы гражданлык хезмәте вазифасының) аталышы, әлеге вазифаны биләүгә дәгъва кылучыга карата белдерелә торган таләпләр, гражданлык хезмәтен үтү шартлары, документларны кабул итү урыны һәм вакыты, аталган документларны кабул итү буенча гамәлдә булган чор, конкурсны үткәрү буенча күздә тотылган дата, аны үткәрү урыны һәм тәртибе, башка мәгълүмати материаллар. Конкурста катнашу өчен документларны кабул итү турындагы игълан һәм конкурс турындагы мәгълүмат шулай ук вакытлы басма матбугатта бастырылырга мөмкин;

граждан (гражданлык хезмәткәре) тапшырган документларны тикшерә;

гражданның (гражданлык хезмәткәренең) квалификация таләпләренә туры килүен тикшерә (һөнәри белем дәрәҗәсе, гражданлык хезмәте (бүтән төрле гражданлык хезмәтенең) стажы яки белгечлеге буенча эшләү стажы (тәҗрибәсе), әзерлеккә юнәлтелүе, вазифаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәре һәм күнекмәләре).

Конкурсның беренче этабы кабул итү турында игълан бастырылганнан соң башлана һәм 21 көннән ким булмаган чорда тәмамлана.

4.4.2. Тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив-хокукый актлары нигезендә гражданның гражданлык хезмәтенә керүенә каршы килә торган шартлар ачыкланган очракта, ул Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан язмача рәвештә конкурста катнаштырудан баш тартуның сәбәпләре хакында хәбәрләштерелә.

4.4.3. Дәүләт комитетында гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъва кылган, ләкин конкурста катнашуга

кертелмәгән зат әлеге карарны Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылырга хокуклы.

4.4.4. Дәүләт комитетында гражданлык хезмәтенең бер вакант вазифасына (кадрлар резервындагы гражданлык хезмәте вазифасына) билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирә торган кимендә ике кандидатның булуы конкурсның беренче этабын төгәлләү шарты булып тора, бу хәл кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаганда яки вазифага карата квалификация таләпләренә җавап бирә торган бары тик бер генә кандидат булган очракта, конкурс узмаган дип танылa. Бу очракта бердәнбер кандидатка конкурс комиссиясенең карары буенча конкурс комиссиясенең таләп ителгән кандидатлар саны булмауга бәйле рәвештә узмаган дип танылуы хакында язмача хәбәр ителә.

4.4.5. Конкурс комиссиясенең күпчелек дәрәҗәдә билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста алга таба катнашуга тәкъдим ителгән кандидатлар исемлеген төзү турындагы карары конкурсның беренче этабының нәтиҗәсе булып санала, әлеге карар конкурс комиссиясенең рәисе тарафыннан раслана.

4.4.6. Конкурсның беренче этабы узгач, Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан конкурсның икенче этабын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында карар кабул ителгәч, конкурс комиссиясе конкурсның икенче этабын үткәрә.

Дәүләт комитетының кадрлар һәм юридик эш секторы, конкурсның икенче этабы башланганчыга кадәр 15 көннән соңга калмыйча, конкурстка катнашуга кертелгән гражданнарга (гражданлык хезмәткәрләренә) аның үткәрелү датасы, урыны һәм вакыты турында хәбәрләр җибәрә.

4.4.7. Конкурсның икенче этабында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

а) конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләнә;

гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс комиссиясендә җиңүчене билгеләү турында Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан карар кабул ителә;

4.4.8. Конкурсны үткәргәндә конкурс комиссиясе кандидатларны алар тарафыннан тапшырылган белем, гражданлык яки бүтән гражданлык хезмәтен үтү, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турындагы документлары нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган, кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларыннан кулланып, конкурс процедуралары нигезендә, шул исәптән Дәүләт комитетында гражданлык хезмәтенең вакант вазифасы (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазифасы) буенча вазифаи бурычларны үтәүгә бәйле булган мәсьәләләрдә тест һәм шәхси әңгәмә үткәрү юлы белән бәяли.

4.4.9. Кандидатларны Дәүләт комитетында гражданлык хезмәтенең билгеле бер вакант вазифасына (кадрлар резервындагы гражданлык хезмәте вазифасына) буенча кандидатларга тест үткәрү Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының 2016 елның 11 гыйнварындагы № 1 карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте

вазифаларын биләүгә дәгъвалык итүче гражданнарга тест үткәрү методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.4.10. Тест үткән кандидатлар белән шәхси әңгәмәләр конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан үткәрелә.

Шәхси әңгәмә булачак һөнәри хезмәт итү эшчәнлеге темасы буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бирелә торган сорауларга кандидатларның җавапларыннан гыйбарәт, әңгәмә барышында конкурс комиссиясе кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын гражданлык хезмәте вазифасына һәм әлеге вазифа буенча вазифаи регламентның бүтән нигезләмәләренә, шулай ук әлеге Нигезләмәдә һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турындагы законнарында билгеләнгән бүтән нигезләмәләргә карата тиешле квалификация таләпләреннән чыгып бәяли.

4.5. Конкурс комиссиясенең конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелгән карары конкурсның икенче этабы нәтиҗәсе һәм бер үк вакытта конкурсның йомгаклау нәтиҗәсе булып тора.

4.6. Кандидатлар тарафыннан алынган тавышларның саны, структур кандидатлар шундагы вазифага дәгъва кыла торган бүлекчә җитәкчесенең (Дәүләт комитеты җитәкчелегенең) фикере Дәүләт комитетында гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидат турында карарны кабул итү һәм конкурска йомгак ясау өчен нигез булып торалар.

"Риза" тавышларын иң күп җыйган кандидат конкурста җиңүче дип танылa.

4.7. Әгәр дә конкурсны үткәрү нәтиҗәсендә гражданлык хезмәтенең вакант вазифасы (кадрлар резервындагы гражданлык хезмәте вазифасы) буенча барлык кирәкле таләпләргә җавап бирә торган кандидатлар ачыкланган очракта, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынауларын үткәрү турында карар кабул итәргә яки яңа конкурсны үткәрү турында тәкъдим итәргә хокуклы.

4.8. Гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә карата конкурс нәтиҗәләре буенча Дәүләт комитетының гражданлык хезмәтенең вакант вазифасына конкурста җиңүчене билгеләү турындагы боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә. Конкурс комиссиясе шулай ук тәкъдим холкына ия булган, гражданлык хезмәтенең вакант вазифасына карата конкурста җиңмәгән, ләкин һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәягә лаек булган кандидатны Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә хокуклы.

Кандидат ризалыгы белән Дәүләт комитетының аны гражданлык хезмәтенең вакант вазифасы карый торган шул ук төркемдәге гражданлык хезмәте вазифасын биләү буенча кадрлар резервына кертү турында боерыгы чыгарыла.

Гражданлык хезмәткәрен (гражданны) – конкурста җиңүчене кадрлар резервына кертү Дәүләт комитеты боерыгы нигезендә рәсмиләштерелә, Дәүләт комитеты боерыгының күчермәсен гражданлык хезмәткәренең шәхси эшенә теркәп.

4.9. Гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидат конкурс комиссиясе карарын Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылырга хокуклы.

4.10. Конкурс нәтиҗәләре турындагы хәбәрләр конкурста катнашучыларга конкурс тәгәлләнгәннән соң 7 көнлек чорда язмача рәвештә җибәрелә. Шулай ук

конкурс нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат аталган чорда Дәүләт комитетының рәсми сайтында һәм "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәренең дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

4.11. Дәүләт комитетында гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъва кылган, ләкин конкурста катнашуга кертелмәгән кандидатларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары язма гариза буенча конкурс тәмамланган көннән соң өч ел дәвамында аларга кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге чор тәмамланганчыга кадәр документлар Дәүләт комитеты архивында саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

4.12. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрелгән урынга бару һәм кайту, торак бинага түләү, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкасы) кандидатлар тарафыннан үз акчалары хисабыннан каплана.

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 15.09.2016 № 87 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс үткәрү турында нигезләмәгә карата 1 кушымта

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисенә

___________________________________

(инициаллары, фамилиясе)

Хезмәт язуы

Сездән Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс игълан итүегезне сорыйм

______________________________________________________________________

(вазифасының атылышы)

______________________________________________________________________

(бүлек аталышы)

Аталган вакант вазифаны биләүгә (аталган вазифа буенча кадрлар резервына кертелүгә) дәгъва кылучыга карата түбәндәге таләпләр куела:

белеме буенча – ______________________________________________________

дәүләт хезмәтендәге стажы һәм эш тәҗрибәсе буенча –_________________________

__________________________________________________________________

күнекмәләре һәм белемнәре буенча –______________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Структур бүлекчә җитәкчесе

____________ ______________________________________

(дата) (имза, имзаның аңлатмасы)

Килештерелде:

Рәис урынбасары

________ ________________________________________

(дата) (имза, имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 15.09.2016 № 87 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс үткәрү турында нигезләмәгә карата 2 кушымта

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисенә

______________________________________
(инициаллары, фамилиясе)

кемнән_______________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

белеме ____________________________,
(төре, белем йорты, тәмамлаган елы)

яшәгән адресы: _____________________

______________________________________,

тел.________________________________,
(эшнеке, өйнеке, кесә)

e-mail ____________________________________

Гариза

Мине Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурста катнашырга кертүегезне сорыйм

________________________________________________________________
(вазифасының атылышы)

________________________________________________________________
(структур бүлекчәнең аталышы)

2004 елның 27 июлендәге "Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында" № 79-ФЗ Федераль закон, 2003 елның 16 гыйнварындагы "Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте турында" № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге "Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә карата конкурс турында" № 112 указы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турындагы бүтән норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант

вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс үткәрү турындагы нигезләмә, шул исәптән аталган вазифага карата билгеләнә торган квалификация таләпләре белән таныштым.

Дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга карата рөхсәт алуны рәсмиләштерү процедурасы үткәрелүгә ризамын.

Конкурсны үткәрү датасы һәм урыны турында e-mail яки күрсәтелгән кесә телефоны номерына СМС-хәбәр ярдәмендә хәбәр алуга ризамын.

Гаризага түбәндәгеләрне терким: (теркәлә торган документларны санап чыгарга).

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

_______________________ _______________________ _______________________

(дата) (имза) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 15.09.2016 № 87 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс үткәрү турында нигезләмәгә карата 3 кушымта

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында
Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча кандидатларга карата таләпләр

1. Гомуми таләпләр

1.1. Россия Федерациясенең 18 яшенә җиткән, Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән, Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләү (кадрлар резервына кертелү) өчен кирәкле булган таләпләргә җавап бирә торган гражданнары Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурста катнашырга хокуклы.

Гражданлык хезмәткәре гомуми нигезләрдә Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурста аны үткәрү чорында нинди вазифаны биләвенә бәйсез рәвештә катнашырга хокуклы.

1.2. Граждан түбәндәге очракларда Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурста катнашырга кертелми:

1) законлы көченә кергән суд карары нигезендә ул хезмәткә яраксыз яки эшкә яраклылык сәләте чикләнгән дип танылганда;

2) законлы көченә кергән суд карары буенча дәүләт хезмәте (гражданлык хезмәте) вазифасы буенча вазифаи бурычларны башкару мөмкинлеген юкка чыгара торган җәзага хөкем ителгәндә, шулай ук аңа карата федераль законда билгеләнгән тәртиптә алынмаган яки капланмаган суд хөкеме булганда;

3) дәүләт серен яки закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт бирү процедурасын үтүдән баш тартканда, әгәр дә граждан биләүгә дәгъва кыла торган Татарстан Республикасы

гражданлык хезмәте вазифасы буенча яки Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәре тарафыннан биләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифасы буенча вазифаи бурычларны башкару мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булса;

4) Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачаулый торган һәм медицина оешмасының бәяләмәсе белән расланган чирнең булуы (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге № 984н боерыгы белән расланган 001-ГС/у исәп рәвеше);

5) Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәре белән якын туганлыкта яки үги туганлыкта (ата-анасы, тормыш иптәше, балалары, ир туганнары, кыз туганнары, шулай ук тормыш иптәшенең ир туганнары, кыз туганнары, ата-анасы, балалары һәм балаларының тормыш иптәшләре) булганда, әгәр дә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифасын биләү беренчесенең икенчесенә турыдан-туры буйсынуына яки контрольлегендә булуына бәйле булса;

6) Россияя Федерациясе гражданлыгыннан чыгу яки башка дәүләт гражданлыгын алу;

7) башка дәүләт (башка дәүләтләрнең) гражданлыгында булу, әгәр дә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкача каралмаган булса;

8) Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә кергәндә ялган документлар яки белә торып ялган белешмәләр тапшырганда;

9) Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә кергәндә керемнәре турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында 2004 елның 27 июлендәге "Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында" № 79-ФЗ Федераль законда билгеләнгән белешмәләрне тапшырмаганда яки белә торып ялган белешмәләр тапшырганда;

10) моңа чакырылыш комиссиясе бәяләмәсе нигезендә законлы нигезләре булмый торып, ул чакырылыш буенча хәрби хезмәтне үтмәгән дип танылганда (контракт буенча хәрби хезмәт үткән гражданнардан кала);

11) мәнфәгатьләр каршылыгын юкка чыгару турында яки җайга салу турындагы чикләмәләрне һәм тыюларны, таләпләрне үтәмәгән очракта һәм коррупциягә каршы көрәшү максатларында 2004 елның 27 июлендәге "Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында" № 79-ФЗ Федераль законда, 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы көрәш турында" № 273-ФЗ Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән бурычларны үтәмәгәндә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә карата эшкә яллаучының вәкиле тарафыннан ышаныч беткәндә.

## 2. Квалификация таләпләре

2.1. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренең белеменә һәм стажына яки эш стажына (тәҗрибәсенә) карата квалификация таләпләре:

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең барлык категорияләрендәге баш вазифалар – югары һөнәри белем, гражданлык хезмәтенең әйдәп баручы яки өлкән төркемнәрендәге вазифаларында кимендә ике еллык дәүләт

хезмәте стажы яки белгечлеге, эзерлек юлламасы буенча кимендә өч еллык эш стажы булу;

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең барлык категорияләрендәге әйдәп баручы вазифалар – югары һөнәри белем, гражданлык хезмәтенең өлкән яки кече төркемнәрендәге вазифаларында кимендә бер еллык дәүләт хезмәте стажы яки белгечлеге, әзерлек юлламасы буенча кимендә ике еллык эш стажы булу;

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең "белгечләр" категориясендәге өлкән вазифалар – стажына карата таләпләр куелмыйча, югары һөнәри белемгә ия булу;

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең "тәэмин итүче белгечләр" категориясендәге өлкән вазифалар – стажына карата таләпләр куелмыйча, эшчәнлеге буенча урта һөнәри белемгә ия булу;

2.2. Вазифаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренең вазифаи регламентында һәм Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2015 елның 09 июнендәге "Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары буенча вазифаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләрен раслау турында"гы № 67 боерыгында билгеләнде.

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 15.09.2016 № 87 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс үткәрү турында нигезләмәгә карата 4 кушымта

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурсында катнашучыларны бәяләү критерияләре

1. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте мәдәниятенә туры килүе

1.1. Һөнәри максатчанлык

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтендә үзеңне һөнәреңдә тормышка ашыруга омтылу, дәүләт идарәлеге өлкәсендә хезмәттә үсүгә юнәлеш алу.

1.2. Гражданлык позициясе

Эшчәнлектә җәмгыятькә һәм дәүләткә хезмәт итү, законнарны, хезмәт этикасы кагыйдәләрен саклау принципларын үтәү.

1.3. Һөнәри позициядәге активлык

Куелган мәсьәләләрне хәл иткәндә инициатива күрсәтергә омтылу; мөмкин булган иң яхшы нәтиҗәгә ирешү өчен хәлдән килгән көчне кулланырга әзер булу, физик һәм эмоциональ басым шартларында нәтиҗәле эш-гамәл кылуга сәләтле булу (стрессларга каршы торучанлык).

1.4. Үз-үзеңне үстерүгә әзер булу

Үз белемнәреңне, белгәннәреңне һәм күнекмәләреңне даими камилләштерергә, карашларыңны киңәйтергә, катнаш һөнәр өлкәләрендәге белемнәрне һәм тәҗрибәне алырга омтылу.

2. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренең һөнәри вәкаләтчелеге

2.1. Белем алу дәрәҗәсе

Төп һәм өстәмә һөнәри белеменең дәрәҗәсе, юнәлеше һәм сыйфаты

2.2. Һөнәри тәҗрибәсе

Тиешле һөнәр өлкәсендәге эшчәнлегенең озынлыгы һәм үзенчәлекләре; һөнәри эшчәнлегендә билгеле бер нәтиҗәләргә ирешүе; карьерасының үзенчәлекләре.

2.3. Махсус һөнәри белемнәре, белгәннәре һәм күнекмәләре

Тиешле өлкәдә, вазифаи бурычларны нәтиҗәле башкару мөмкинлеген бирә торган һөнәри белемнәренең дәрәҗәсе; һөнәри эшчәнлекне регламентлый торган Россия Федерациясе законнарын белүе; заманча һөнәри технологияләр белән эш итә белүе.

2.4. Гомуми кораллы күнекмәләр

Һөнәри эшчәнлекнең гомуми нәтиҗәлелеген арттыра торган күнекмәләргә ия булу дәрәҗәсе (компьютерны белү, гомуми грамоталыгы, чит телләрне белү һ. б.).

## 3. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренең шәхси-эшлекле сыйфатлары

3.1. Аналитикага бәйле сәләтләре

Фикерләүнең катлаулы, мәгълүматны анализлауны һәм структурлаштыруны таләп итә торган системалылык һәм сыгылмалылык дәрәҗәсе; бүтән, гадәти булмаган чишелеш табу сәләте.

3.2. Нәтиҗәле коммуникацияләү күнекмәләре

Эшлекле аралашу этикасын саклау; үзеңнең шәхси фикереңне аргументлы дәлилле белү һәм оппонентларны ышандыра алу сәләте; эшлекле сөйләшүләрне алып бару күнекмәләренә ия булу.

3.3. Җаваплылык

Караларны кабул иткәндә нигезлелек һәм мөстәкыйльлек; нәтиҗәгә ирешүдә үз өстеңә алынган йөкләмәләрне үтәргә әзер булу.

3.4. Оештыруга бәйле сәләтләре

Үз эшчәнлегеңне һәм сиңа буйсынып эшләүчеләрнең эшчәнлеген нәтиҗәле планлаштыру, вазифаларны, вәкаләтләрне һәм җаваплылыкны бүлеп бирү хисабына нәтиҗәләргә ирешә белү.